БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 июня 2022 ел № 131

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. 2016 елның 16 сентябрендәге 53 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында Нигезләмәгә яңа редакциядә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 пунктның 17 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- тиешле муниципаль районнар территорияләрендә каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерып туплау), җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;";

1.2. 3.2 пунктның 9 абзацта "хокукларны гамәлгә ашыру" сүзләреннән соң "аз санлы җирле халыкларның һәм башкаларның" сүзләрен өстәргә;

1.3. 4.1 пунктның 7 пунктчасындагы 13 абзацта "хокукларны гамәлгә ашыру" сүзләреннән соң "аз санлы җирле халыкларның һәм башкаларның" сүзләрен өстәргә;

1.4. 4.1 пункттагы 5 пунктчаның 12 абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. 4 бүлекнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Башкарма комитет муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) муниципаль район музейларын булдыру;
2) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашу;

3) муниципаль район территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

4) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм муниципаль район территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү;

5) 2008 елның 31 декабренә торышы буенча алар карамагында булган югары белем бирү муниципаль мәгариф оешмалары оештыручысы функцияләрен гамәлгә ашыру;

6) туризмны үстерү өчен шартлар тудыру (пункт өстәмә рәвештә 2008 елның 30 декабреннән 2008 елның 25 декабрендәге 281-ФЗ номерлы федераль закон белән кертелде);

7) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтү;

8) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гомумроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларга ярдәм күрсәтү;

9) "Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында" Федераль законда каралган чараларны гамәлгә ашыру;

10) авылара территориядә урнашкан торак пунктта нотариус булмаганда, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кылу;

11) федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрү;

12) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру;

13) инвалидлар, мөмкинлекләре чикләнгән затлар физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм күрсәтү.";

14) "Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-I номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;

15) участок полиция вәкиле вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү;

16) алкогольдән, наркотиктан яки башка токсиннан исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;

17) муниципаль янгын сагы булдыру.".

5.6.2 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.6. "9) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы - чит ил гражданлыгын туктату, чит ил гражданлыгы (башка илгә буйсынганлыгы) яисә яшәүгә рөхсәт булу яки чит ил дәүләте территориясендә Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган чит ил гражданының даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;".

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе Хәйретдинов Айдар Фоат улына Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10 нчы районара салым инспекциясендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертүне һәм Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында башка үзгәрешләр кертүне теркәгәндә, мөрәҗәгать итүче булырга, бу максатларда кирәкле гаризаларны һәм башка документларны имзаларга, законнарда каралган тәртиптә һәм вакытларда башка гамәлләр кылырга һәм формальлекләрне үтәргә вәкаләт бирергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин